| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.05.2020 с.Старое Дрожжаное № 264

Ызанлау проектын эшләү, килештерү һәм раслау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитет Җитәкчесенең 2007 елның 12 февралендәге 38 номерлы карары (16.10.2018 № 573 редакциясендә) белән расланган ызанлау проектын эшләү, килештерү һәм раслау тәртибе турындагы нигезләмәнең **2.12 пунктына** түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**җиденче абзацны** түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегенең җирле үзидарә органы территорияне планлаштыру буенча документлар кергән көннән алып егерме эш көне эчендә, аны раслау турында карар шәһәр төзелеше кодексы нигезендә авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителә, мондый документацияне шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 10 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән орган территорияне планлаштыру буенча документларны җәмәгать фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда карауны тәэмин итәләр яисә мондый документацияне кире кагалар һәм аны эшләп бетерүгә җибәрәләр»;

сигезенче абзацны **төшереп калдырырга.**

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов